**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

03 апрель 2023 ел № 6

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә файдаланылган терекөмеш лампаларны туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 январендагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Тиешенчә җыймау, тупламау, кулланмау, зарарсызландырмау, транспортламау һәм урнаштырмау гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зарар китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмеш лампаларны туплау урынын (урыннарын) билгеләргә: Яңа поселогында, Үзәк урамы, 1 йорт
2. Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләре, яллаучылары, файдаланучылары булган терекөмөшле лампалар кулланучылардан файдаланылган терекөмөшле лампаларны туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Тиешенчә җыймау, тупламау, кулланмау, зарарсызландырмау, транспортламау һәм урнаштырмау гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зарар китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 14 пункты нигезендә билгеләнә.
3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән файдаланылган терекөмөшле лампаларны туплану урыннары, шул исәптән күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле, терекөмөшле лампалар туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, бу күпфатирлы йортлардагы биналар милекчеләре, яллаучылары, файдаланучылары булган терекөмөшле лампалар кулланучылар өчен дә билгеләнгән.

4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны туплау урыны (урыннары) турында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Тукай район массакүләм мәгълүмат чарасында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Әҗмәкәй авыл җирлеге
җитәкче вазыйфаларын башкаручы Г.Т.Хөсәинова